# Татарстан Республикасы ЗАКОНЫ

**2001–2003 елларга Татарстан Республикасының эш белән тәэмин ителмәгән халкына эш белән тәэмин ителүдә һәм социаль яклануда ярдәм күрсәтү буенча республика программасын раслау турында**

Татарстан Республикасы Конституциясенең 7 һәм 89 статьялары нигезендә Татарстан Республикасының эш белән тәэмин ителмәгән халкына эш белән тәэмин ителүдә һәм социаль яклануда ярдәм күрсәтү буенча республика программасы Татарстан Республикасы дәүләт социаль сәясәтенең иң мөһим элементларыннан берсе була.

**1 статья.** 2001–2003 елларга Татарстан Республикасының эш белән тәэмин ителмәгән халкына эш белән тәэмин ителүдә һәм социаль яклануда ярдәм күрсәтү буенча республика программасын расларга (кушымта итеп бирелә).

**2 статья.** 2002–2003 елларга Татарстан Республикасынын бюджет системасы турында Татарстан Республикасы законнары проектларын әзерләгәндә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты югарыда күрсәтелгән программаны гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасының республика бюджетында акчалар күз алдында тотарга тиеш.

**3 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Ш.Шәймиев

Казан шәһәре,
2002 елның 17 гыйнвары
№ 1284

Татарстан Республикасы
Законына кушымта
2002 елның «17» гыйнвары
№ 1284

**2001-2003 елларда Татарстан Республикасының эш белән тәэмин ителмәгән халкына эш белән тәэмин ителүдә һәм социаль яклануда ярдәм итүнең республика программасы**

**паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2001-2003 елларда Татарстан Республикасының эш белән тәэмин ителмәгән халкына эш белән тәэмин ителүдә һәм социаль яклануда ярдәм итүнең республика программасы |
| Программаны әзерләү өчен нигез | «Халыкны эш белән тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законы |
| Программаны әзерләүче | Татарстан Республикасы Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү министрлыгы |
| Программаны үтәүчеләр | Татарстан Республикасы Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү министрлыгы, Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары, Татарстан Республикасы шәһәрләренең һәм районнарының администрацияләре, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр, Татарстан Республикасының Һөнәр берлекләре федерациясе |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | – хезмәт базарындагы процессларны җайга салучы норматив базаны камилләштерү;<br>– халыкны эш белән тәэмин итүне арттыру өчен уңайлы шартлар тудыру;<br>– эш бирүчеләр белән хезмәттәшлекне активлаштыру;<br>– социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен, шул исәптән яшьләр, уку йортларын тәмамлаганнар өчен эшкә урнашу мөмкинлекләрен киңәйтү; |

71

| | |
|---|---|
| | — һөнәргә өйрәтү, һөнәри ориентация, эшсезләргә һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итү чараларының адреслылыгын тәэмин итү, озакка сузылган эшсезлекнең нәтиҗәләрен киметү, социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм эш урыннарын квоталау юлы белән эш белән тәэмин ителмәгән халыкны социаль яклау |
| Программаны гамәлгә ашыру вакытлары | 2001-2003 еллар |
| Программаны финанслау чыганаклары | Федераль бюджет, Татарстан Республикасының республика бюджеты, җирле бюджетлар, предприятиеләрнең акчалары |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтеләчәк нәтиҗәләре | — 2001 елның азагына официаль эшсезлекнең дәрәҗәсен икътисадый актив халык саныннан 1,14 процент чикләрендә тотып тору, 2002 елда – 1,17 процент, 2003 елда – 1,16 процент;<br>— эшкә урнашу мәсьәләләре буенча елына кимендә 425,0 мең гражданга хезмәт күрсәтү;<br>— 2001 елда 155,0 мең кешегә, 2002-2003 елларда кимендә 95,0 мең кешегә эшкә урнашканда ярдәм итү, шуларның ел саен кимендә 70,0 мене махсус программалар кысаларында;<br>— киләчәктә эшкә урнашу өчен 2001 елда 7,3 мең кешегә, 2002 елда – 8,5 мең кешегә, 2003 елда 9,1 мең кешегә һөнәр осталыгы алу мөмкинлеген тудыру;<br>— 2001 елда – 18,4 мең, 2002 елда – 19,6 мең, 2003 елда 20,0 мең эшсез гражданга айлык керемнәрен алуда ярдәм итү |
| Программаны гамәлгә ашыруны тикшереп тору | Программаны гамәлгә ашыруны Татарстан Республикасы Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү министрлыгы тикшереп тора |

## 2001-2003 елларда Татарстан Республикасының эш белән тәэмин ителмәгән халкына эш белән тәэмин ителүдә һәм социаль яклануда ярдәм итүнең республика программасы

### Кереш

Татарстан Республикасында үткәрелүче социаль сәясәтнең төп максаты – бер үк вакытта икътисадый һәм социаль прогрессны тәэмин итү, ул халыкны нәтиҗәле рәвештә эш белән тәэмин итүгә омтылышны һәм аны социаль яклауның сыгылмалы дәүләт системасы эшчәнлеген күз алдында тота.

2001–2003 елларда Татарстан Республикасының эш белән тәэмин ителмәгән халкына эш белән тәэмин ителүдә һәм социаль яклануда ярдәм итүнең республика программасы икътисадый актив халыкнын эш белән тәэмин ителмәгән өлешенә эшкә урнашуда ярдәм күрсәтүгә һәм аны эшсезлектән социаль яклауга юнәлдерелгән һәм халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә икътисадка индикатив идарә системасы күрсәткечләрен тәэмин итүче төп гамәлләрдән гыйбарәт.

### Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү һәм хезмәт базары

#### 1.1 Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге вәзгыятьне анализлау

Икътисадның торышы белән билгеләнүче республика хезмәт базарындагы вәзгыять тенденцияләре 1999 елда ук барлыкка килгән уңай үзгәрешләр белән характерлана.

2002 елда сәнәга җитештерүенең физик күләме 1999 ел белән чагыштырганда 109,8 процент тәшкил итә. Төп капиталга инвестицияләр 8 ,0 процентка артты. Халыкның акчалата реаль керемнәре арту күзәтелә.

Икътисадтагы үзгәрешләр республика хезмәт базарына да йогынты ясады.

Татарстан Республикасы Дәүләт статистика комитеты белешмәләренә караганда, икътисадый актив халыкның саны 2000 елның декабрендә 1813,1 мең кеше тәшкил иткән, моңа шәхси ярдәмче хуҗалыгында мәшгуль булганнар да керә. Актив рәвештә эш эзләүче, Халыкара хезмәт оешмасы ысулияте буенча эшсез дип исәпләнүче мәшгуль булмаган гражданнар саны 182,3 мең кеше тәшкил итә.

1999 елдан башлап эш белән тәэмин ителгәннәр саны арта. Эш белән тәэмин ителешнең артуы икътисадның барлык тармакларында күзәтелә: авыл хуҗалыгында, сәүдәдә, мәгарифтә, сәламәтлек саклауда, сәнәгадә һәм башкаларда. Эшләүчеләр саны кимү төзелешкә, торак-коммуналь хуҗалыгына, көнкүреш хезмәтенең җитештерми торган төрләренә хас.

2000 елда республикада легаль хезмәт эшчәнлеге белән 2,4 мең чит ил хезмәткәре шөгыльләнгән, шулардан 1,3 меңе 2001 елда да эшләүләрен дәвам итәләр, бу республика икътисадында эш белән тәэмин ителгәннәрнең 0,08 процентын тәшкил итә.

2000 ел эчендә тулы булмаган эш көне режимында 30,8 мең кеше эшләгән, 36,0 мең кеше административ ялда булган (1999 елда шулар ук – 79,1 мең кеше һәм 66,3 мең кеше).

Теркәлгән эшсезләр саны да кими бара. 2000 ел эчендә эшсезләр саны 9,8 мең кешегә кимеде һәм декабрь азагына 19,6 мең кеше тәшкил итә. Теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсе бу чакта республикадагы икътисадый актив халыкның 1,04 процентына тигез.

Территорияләр ягыннан караганда, теркәлгән эшсезлекнең уртача республика дәрәҗәсеннән бу сан түбәндәгеләрдә артык: Чистай шәһәрендә – 2,68 процентка, Чаллыда – 2,47 процентка, Алабугада – 1,87 процентка, Зеленодольскта – 1,71 процентка, Лениногорскта – 1,24 процентка, Мамадыш районында – 1,43 процентка.

2001 елның 1 гыйнварына теркәлгән эшсезләрнең 89,7 процентына эшсезлек пособиесе билгеләнде. Пособиенең уртача күләме 457 сум тәшкил итә.

Хатын-кызлар арасында эш белән тәэмин ителү проблемасы кискенләшә, эшсез хатын-кызлар саны 83,1 процентка артты. Эшсезләрнең

74

5,2 процентка якыны авыл җирендә яши. 16–29 яшьлекләр эшсезләрнең гомуми саныннан 30,6 процент тәшкил итә, пенсия яшенә җитеп килүчеләр – 13,9 процент. Эшсезләр структурасында гарипләрнең өлеше дә 6,8 процент тәшкил итә.

Эшсезләрнең 37,8 процентын үз теләге белән эштән киткәннәр тәшкил итә, хезмәткәрләрнең эштән азат ителгәннәре арасында теркәлгәннәр саны икеләтә ким (гомуми саннан 19,9 процент).

Югары һөнәр белеменә эшсезләрнең 14,1 проценты ия, урта һөнәр һәм тулы булмаган югары белемгә – 29,9 проценты, башлангыч һөнәр белеменә – 18,3 проценты. Эшсезләрнең һөнәри составын анализлау күрсәткәнчә, хезмәт базарында эшче көче тәкъдимен тәшкил итүче төп һөнәрләр соңгы берничә елда үзгәрми диярлек. Эшче һөнәрләре арасында сатучыларга, контролерларга, тегүчеләргә һәм пешекчеләргә эшкә урнашуы авыррак. Хезмәткәрләр арасыннан–бухгалтерларга, инженерларга, техникларга, икътисадчыларга, тәрбиячеләргә. Эшсезләрнең 9 проценты бөтенләй һөнәрсез.

Эшсезләрнең икенең бере каравында балигъ булмаган балалары бар.

Төрле уку йортларын тәмамлаганнар эшсезләрнең 7,2 процентын тәшкил итә, шуларның 70 проценты – һөнәр уку йортларын тәмамлаганнар. Эшсезләр статусына 175 һөнәр уку йортын тәмамлаганнар ия, шул исәптән 31 е – югары уку йортын (22 се - республика югары уку йортын), 73 е – урта һөнәр белеме учреждениесен, 71 е – башлангыч һөнәр белеме учреждениесен тәмамлаганнар.

Хезмәт базарындагы унай үзгәрешләргә эшче көчләргә ихтыяҗ арту да керә. Эшче көчләргә ихтыяҗның гомуми күләме (эш белән тәэмин ителгәннәр саны һәм кадрларга карата игълан ителгән ихтыяҗ) 2000 елда 1670,5 меңнән 1695,9 мең кешегә артты.

2001 елның 1 гыйнварына игълан ителгән вакансияләр саны 17,9 процент тәшкил итте. Нәтиҗәдә хезмәт базарындагы киеренкелек коэффициенты (халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләрендә исәптә торган эш белән тәэмин ителмәгән халык санының предприятиеләр һәм оешмалар игълан иткән хезмәткәрләр санына чагыштырмасы) 2000 ел башында бер

вакансиягә 2,8 кешедән декабрь азагына 1,2 кешегә кимеде. Ягъни халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләрендә теркәлгән эшсезләр санына туры килә.

Эш урыннарының артуы хезмәт базарын сан ягыннан баланслады, әмма ул эшче көчләрнең санын, сыйфатын һәм хакын вакытында үзгәртү проблемасын хәл итмәде. Хезмәт өчен түләүнең тәкъдим ителүче түбән күләме вакансияләр арту белән бергә барды, йә хезмәт хакын түләүне тоткарлау очраклары булды, ташламалар, гарантияләр һәм эш белән тәэмин итүдә тотрыклылык булмады. Күп кенә ачык вакансияләр эшсезләрнең һөнәри осталыкка һәм квалификациягә ия булмаулары аркасында буш калды. Гомуми ихтыяжда бары тик ирләр өчен генә эш урыннары булу сәбәпле (80 процент), эш урыннары буш калды, чөнки эшсезләрнең 83 проценты – хатын-кызлар. Нәтиҗәдә эшсезлекнең гомуми чоры 2001 елның 1 гыйнварына 6,8 ай тәшкил итте.

Квалификацияле кадрларның җитмәве һәм картаюы проблемасы көннән-көн кискенләшә. Җитештерү кимегән чорда мобиль квалификацияле кадрлар кече һәм урта бизнеска китә йә «соры» хезмәт базарына күчә, анда керемнәр дә артык, тотрыклылык та бар. Җитештерүнең җәлеп ителешен, эшче һөнәрләрнең абруен аеруча яшьләр арасында арттырырга кирәк.

## 1.2 Эш белән тәэмин итү өлкәсенең перспективалары

Татарстан Республикасының Икътисад һәм сәнәга министрлыгы фаразларына караганда, 2001 – 2003 елларда сәнәга продукциясенең күләме артачак. Эш белән тәэмин ителүгә республика Хөкүмәтенең инвестиция эшчәнлеген активлаштыру, икътисадның нигези тармакларын сәламәтләндерү, предприятиеләрнең икътисадый үзҗитүчәнлеге механизмын кертү гамәлләре сизелерлек йогынты ясады.

Якындагы елларда халыкны эш белән тәэмин итү дәрәҗәсен үстерү (икътисадый актив халык арасында эшләүчеләр өлешен арттыру) һәм гомуми эшсезлек дәрәҗәсен киметү максат итеп куела. 2003 ел азагына

гомуми эшсезлек дәрәҗәсе 8,3 процентка кимиячәк, ә эш белән тәэмин ителү дәрәҗәсе 91,7 процентка артачак.

Фаразланучы чорда хезмәт базары эшче көчләрнең динамик үзгәрешләре (эш белән тәэмин ителеш, эшсезлек, икътисадый активсызлык) белән характерланачак.

Эшче көчләр тәкъдимен тәшкил итүче төп контингент эш белән тәэмин ителмәгән халык булачак, аеруча – үз теләге белән эштән киткән һәм эштән азат ителгән хезмәткәрләр. Фаразларга караганда, эш белән тәэмин ителмәгән эшче көчләр тәкъдименең гомуми саны, теркәлгән эшсезләрнең «үзгәрүчән» санын исәпкә алып, 96–97 мең кеше тәшкил итәчәк.

Эш белән тәэмин ителүгә ярдәм күрсәтүнең төп юнәлешләре буенча теркәлгән эшче көчләр тәкъдименең 72–76 проценты чамасы яңадан бүленәчәк.

Теркәлгән эшсезләр санын тотыру резервы – теркәлмәгән эшче көчләр тәкъдиме булачак. 2000 елда сайланып алынган рәвештә тикшеренүләрнең нәтиҗәләре күрсәткәнчә, теркәлмәгән хезмәт мөнәсәбәтләре 280 мең кешегә хас, бу 1999 ел белән чагыштырганда кимрәк. Хезмәт өчен түләүне арттыру буенча Хөкүмәт кабул иткән гамәлләр, хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны тикшереп тору, федераль дәрәҗәдәге салым реформалары киләчәктә формаль булмаган эш белән тәэмин ителеш масштабларын һәм халыкның исәпкә алынмаган керемнәрен киметәчәк. Хезмәтнең «соры» базарын республика икътисадына яраклаштыру, теркәлгән эшсезләр санын арттырмыйча гына, легаль булмаган хезмәткәрләрне официаль рәвештә эш белән тәэмин ителгәннәр разрядына күчерергә ярдәм итәчәк.

## 2. 2001-2003 елларда Татарстан Республикасының эш белән тәэмин ителмәгән халкына эш белән тәэмин ителүдә һәм социаль яклануда ярдәм итүнең республика программасының төп максатлары һәм бурычлары

Программаның төп максаты эш белән тәэмин ителүгә ярдәм күрсәтүдән һәм эш белән тәэмин ителмәгән халыкка эш эзләү чорында

77

социаль яклау тәэмин итүдән гыйбарәт. Моннан чыгып, Программа хәл итәргә тиешле түбәндәге бурычлар билгеләнә:

– хезмәт базарындагы процессларны җайга салучы норматив базаны камилләштерү;

– халыкны эш белән тәэмин итүне арттыру өчен уңайлы шартлар тудыру;

– эш бирүчеләр белән хезмәттәшлекне активлаштыру;

– социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен, шул исәптән яшьләр, уку йортларын тәмамлаганнар өчен эшкә урнашу мөмкинлекләрен киңәйтү;

– һөнәргә өйрәтү, һөнәри ориентация, эшсезләргә һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итү чараларының адреслылыгын тәэмин итү, озакка сузылган эшсезлекнең нәтиҗәләрен киметү, социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм эш урыннарын квоталау юлы белән эш белән тәэмин ителмәгән халыкны социаль яклау.

### 3. Эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү һәм аны үстерү

Хезмәт базарында дәүләт сәясәте алдагы чорда түбәндәгеләргә юнәлдереләчәк:

– эшче көчләр һәм эш урыннары саны тәкъдимнәренең тәңгәллегенә ирешүгә;

–эшсезлекнең кинәт артып китүен кисәтүгә;

– хезмәт шартлары һәм хезмәт өчен түләү күзлегеннән гамәлдәге эш урыннарының нәтиҗәлелеген арттыру һәм яңа эш урыннарын булдыруга;

– һөнәри уку системасын, кадрларны яңадан әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү системасын камилләштерү юлы белән кадрлар потенциалын үстерүгә;

– хезмәт ресурсларының мобильлелеген арттыруга.

Бу максатларда түбәндәгеләрне үтәү кирәк:

– булган эш урыннарыннан файдалануны, кече предприятиеләр үсешен, перспектив үсеп килүче тармакларга, шулай ук традицион

мәшгульлек тармакларына да капитал салуларны юнәлтүне киңрәк кызыксындыра торган тәңгәлләштерелгән инвестиция һәм салым сәясәте алып бару ярдәмендә эш урыннары кытлыгын бетерү;

– барыннан да элек хезмәт базарында киеренке вәзгыятьле төбәкләрдә эшкуарлык, кече һәм урта бизнес, индивидуаль эшкуарлык эшчәнлеге үсешен икътисадый кызыксындыру;

– хезмәт базарында киеренке вәзгыятьле шәһәрләрдә һәм районнарда, күппрофильле шәһәрләрдә эш белән тәэмин итүне тотрыкландыру буенча махсус программалар әзерләү;

– югары сыйфатлы эшче көчләр формалаштыруның прогрессиврак чарасы буларак, тоташ белем бирү системасын алга таба үстерү;

– хезмәт шартларын, хезмәт хакын һәм эш вакытыннан файдалану мәсьәләләрен кертеп, эш тиреләге сыйфатын яхшырту;

– югары квалификацияле хезмәткәрләрнең кадрлар потенциалын саклау, булган эш урыннарыннан нәтиҗәле файдалану;

– халыкны эш белән тәэмин итүгә йогынты ясау күзлегеннән чыгып, максатчыл һәм инвестиция программаларына социаль экспертизалар үткәрү.

### 3.1 Эшкә урнаштыруда ярдәм итү

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренең төп көче эш бирүчеләр белән үзара эшчәнлек рәвешләрен камилләштерүгә һәм әлеге вакансияләрнең белешмәләр банкын тулыландыруга, аны нәтиҗәле файдалануга, гражданнарның яраклы эш эзләү вакытын һәм озак эшсезлек чорын кыскартуга юнәлдереләчәк.

2001 елда барлыгы 155,0 мең кеше, 2002 – 2003 елларда 95,0 мең кеше эшкә урнаштырылачак дип фараз ителә.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре эшчәнлеге түбәндәгеләргә юнәлдереләчәк:

— эшкә урнаштыру мөмкинлекләре турында халыкка җиткерү өчен вакансияләрнең белешмәләр банкын формалаштыру һәм аңа ярдәм итү эшен камилләштерүгә;

— эш эзләүче гражданнар өчен һәм эш бирүче таләбе буенча яраклы хезмәткәрләр өчен яраклы эш урыннарын сайлауга;

— эш һәм уку урыннары вакансияләре ярминкәләрен оештыру һәм үткәрүгә;

— озак вакыт эшсез торган гражданнарга эшкә урнашуда ярдәм итү буенча «Эш эзләүчеләр клубы», «Яңа старт» махсус программалары кысаларында эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны эшне актив эзләү күнекмәләренә өйрәтүгә һәм психологик ярдәм итүгә;

— социаль ярдәмгә аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыруның махсус чараларын күрүгә;

— халыкны эш белән тәэмин итүнең шәһәр һәм район үзәкләренең эшкә урнаштыруда гражданнарга ярдәм итү буенча гамәлдәге эш тәртибен камилләштерүгә.

**Балигъ булмаган гражданнарның эш белән вакытлыча тәэмин ителеше**

Хезмәткә җәлеп итү, һөнәри күнекмәләр алу, хезмәт эшчәнлегенә яраклашу максатларында 2001 елда - 129,0 мең,2002 елда - 58,1 мең, 2003 елда 120,0 шәр мең балигъ булмаган гражданны эшкә урнаштыру фараз ителә.

Әлеге максатларда эшкә урнаштыру тәртибен һәм шартларын камилләштерү, әлеге процесска кызыксынучы якларның (эш бирүчеләр,башкарма хакимиятнең җирле органнары, мәгариф системасы органнары, балалар һәм яшьләр эшләре комитетлары) максималь санын җәлеп итү эше дәвам ителәчәк.

**Җәмәгать эшләрен оештыру**

Хезмәт базарын җайга салу ысулларыннан гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру, беренче чиратта җәмәгать эшләренә урнаштыру,

халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтүнең өстенлекле юнәлеш исәбенә керә.

Җәмәгать эшләренә 2001 елда 4,0 мең кешене,2002 – 2003 елларда 5,0 мең кешене җәлеп итү күздә тотыла. Эшсезлек буенча пособие алмый торган, шулай ук халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләрендә 6 айдан артык исәптә торучы гражданнар бу хокуктан файдалануда өстенлекле хокукка ия булачак.

Җәмәгать эшләренең өстенлекле юнәлешләре түбәндәгеләр:

авыл хуҗалыгы продукциясен әзерләү, эшкәртү һәм саклау;

торак фондын, социаль-мәдәни объектларны реконструкцияләү, тарих-архитектура ядкәрләрен,комплексларын,тыюлык зоналарын торгызу;

өлкәннәрне,инвалидларны,авыруларны карау;

территорияләрне яшелләндерү һәм төзекләндерү;

җәмгыяви-мәдәни чаралар үткәрү;

2002 елда Бөтенроссия халык санын алу эше һәм хезмәт эшчәнлегенең башка мөмкин төрләре.

Җәмәгать эшләрен финанслау чыганаклары Татарстан Республикасының республика бюджеты,җирле бюджет акчаларыннан һәм предприятиеләрнең үз акчаларыннан гыйбарәт булырга тиеш.

## Эш белән тәэмин ителмәгән халыкның эшкуарлык инициативасына ярдәм итү

Кече эшкуарлык эшчәнлегенең үсеше эре, икътисадый тотрыксыз һәм перспективасыз предприятиеләргә халыкның эш белән тәэмин ителеше бәйлелеген, эшсезлек янауны киметә, өстәмә эш урыннары булдырырга мөмкинлек бирә. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре тарафыннан ел саен 300 эшсез гражданга эшкуарлык инициативасы ярдәме күрсәтеләчәк.

Эшкуарлык инициативасы ярдәменең төп юнәлешләре буларак түбәндәгеләр билгеләнәчәк:

– эш белән тәэмин ителмәгән гражданнарның эшкуарлар сыйфатында нәтиҗәле эшчәнлек мөмкинлекләрен билгеләү максатларында аларга киңәш һәм һөнәри юнәлеш бирү;

– эшсез гражданнарга эшкуарлык эшчәнлеге нигезләрен, эшкуарлык эшчәнлеге үсешенә ярдәм итүче һөнәрләрне, белгечлекләрне өйрәтү;

– эшсезләргә эшкуарлык эшчәнлегенең башлангыч стадиясендә мәгълүмати, финанс һәм оештыру ярдәмен күрсәтү;

– башлангыч эшкуарларга уку-укыту, консультатив хезмәтләр һәм оештыру ярдәме күрсәтү буенча социаль-эшлекле үзәкләр эшчәнлеген арттыру ;

– эшкуарлык эшчәнлеге үсеше һәм аңа ярдәм итү мәсьәләләре буенча кызыксынучы оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итү.

### 3.2 Эшче көчләрнең сыйфатын үстерү

Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтүнең дәүләт сәясәтендәге төп бурычларының берсе - кадрларны яна һөнәргә өйрәтү һәм тоташ укыту юлы белән хезмәт базарында эшче көчләрнең сыйфатын арттыру һәм конкурентлык тудыру. Бу бурычны гамәлгә ашыру өчен түбәндәгеләрне үтәргә кирәк:

– эшсез гражданнар өчен мәгариф хезмәт күрсәтүләре системасы үсешен тәэмин итү;

– һөнәри белем бирү учреждениеләрендә квалификацияле эшчеләр һәм белгечләр әзерләү күләмен һәм юнәлешләрен җайга салу;

– кадрларның квалификациясен арттыру һәм өйрәтү буенча эчке җитештерү системасын үстерү;

– эштән азат ителгән хезмәткәрләрне алдан өйрәтүне оештыруга ярдәм итү;

– кече һәм урта бизнес предприятиеләре өчен кадрлар әзерләү.

Эшсез гражданнарның һөнәри белем алу хокукларын гамәлгә ашыру хезмәт базарында түбән конкуренциягә ия һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны укытуга, һөнәргә өйрәтүгә һәм аларның

квалификацияләрен күтәрүгә юнәлдереләчәк. Эш бирүчеләр заказлары буенча эшсез гражданнарны конкрет эш урыннарына әзерләү һәм шулай ук эшкуарлык эшчәнлеге, индивидуаль хезмәт эшчәнлеге белән шөгыльләнү мөмкинлеге бирә торган профессияләргә өйрәтү күздә тотыла.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренең мөһим юнәлешләреннән берсе - ел саен квалификацияле эшчеләр һәм белгечләр әзерләү буенча республика ихтыяҗын һәм күләмнәрен билгеләү, шулай ук һөнәри белем бирү учреждениеләрендә аларның күләмнәрен һәм юнәлешләрен килештерү санала.

Җитештерүнең үзендә өйрәтү системасын үстерү максатларында җитештерүнең үзендә персоналны әзерләүдә һәм квалификацияләрен күтәрүдә эш бирүчеләргә мәгълүмати һәм уку-укыту хезмәтләре күрсәтеләчәк. Профессиональ стандартларның таләпләре нигезендә республикада персоналны сертификацияләү системасы эшләрен башкару күздә тотыла.

Эшсезлеккә дучар ителү чорын кыскарту һәм хезмәт базарында социаль киеренкелекне йомшарту максатларында эштән азат ителергә тиешле хезмәткәрләрне киңәш һәм белем бирү юлы белән алдан өйрәтүне оештыруда эш бирүчеләргә ярдәм итү күздә тотыла.

### 3.3 Халыкны һөнәри ориентацияләү һәм аңа психологик ярдәм

Халыкны һөнәри ориентацияләү һәм аңа психологик ярдәм – халыкны социаль яклауның һәм эш белән тәэмин ителешенең гамәли механизмы, икътисадны реформалау шартларында хезмәт базарында җайга салуның бер рәвеше булып тора һәм эшче көчләрнең сыйфатын үстерергә ярдәм итә.

Һөнәри ориентациянең һәм психологик ярдәмнең дәүләт системасы эшчәнлеген тәэмин итү өчен түбәндәге чаралар күз алдында тотыла:

– һөнәри ориентация һәм психологик ярдәм мәсьәләләре буенча кызыксынучы структуралар белән: министрлыклар, ведомстволар, комитетлар, фәнни һәм мәгариф учреждениеләре белән үзара эшчәнлекне киңәйтү;

83

– республика халкын эш белән тәэмин итү үзәкләрендә һөнәри ориентация һәм психологик ярдәм буенча комплекслы хезмәт күрсәтүне тәэмин итү;

– мәгариф учреждениеләре укучылары һәм чыгарылыш укучылары белән һөнәри ориентациядә эшне активлаштыру;

инвалидларның, хәрби хезмәттән азат ителгән хәрби хезмәткәрләрнең иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат гражданнарның һәм социаль яклауга аеруча мохтаж башка категория гражданнарның һөнәри ориентациясе;

– һөнәри юнәлеш, психологик ярдәм һәм хезмәткәрләрне сайлау мәсьәләләре буенча эш бирүчеләргә хезмәтләр күрсәтү.

2001 – 2003 елларда һөнәри юнәлешне һәм психологик ярдәмне – 240,0 меңнән артык гражданга, шул исәптән 2001 елда 61,0 мең гражданга күрсәтү планлаштырыла.

Моның өчен халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләрендә түбәндәге һөнәри хезмәтләр күрсәтү өчен кадрлар белән тәэмин итү һәм эш шартлары тудыру күздә тотыла:

– хезмәт базарында вәзгыять турында, һөнәри белем һәм хезмәткә урнашу мөмкинлекләре турында мәгълүмат бирү;

– эшчәнлек өлкәсен сайлау буенча, һөнәри укыту, яраклы эш сайлау буенча һөнәри консультацияләр үткәрү;

– хезмәт базарына яраклашу һәм эшне нәтиҗәле эзләү күнекмәләренә өйрәтү максатларында психологик ярдәм итү.

## 3.4 Махсус ихтыяҗлары булган гражданнарның социаль интеграциясе һәм аларга ярдәм итү

### Яшьләрнең эш белән тәэмин ителеше

Хезмәт юлына аяк басучы яшьләрне эшкә урнаштыру өчен шартлар тудыру һәм эшсез яшьләргә эш эзләү чорын киметү иң мөһим бурычларның

берсе булып тора. Яшьләрне эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өчен түбәндәге чаралар күз алдында тотыла:

– эш эзләү күнекмәләренә өйрәтүне дә кертеп, мәгариф учреждениеләрендә һөнәри ориентация курсларын булдыру;

– гомуми белем бирү учреждениеләренең чыгарылыш укучыларына һөнәри белем бирү учреждениеләрендә уку мөмкинлекләре, киләчәктә эшкә урнашу өчен өстәмә һөнәрләргә өйрәнү турында, шул исәптән вакансияләр һәм уку урыннары ярминкәләре оештыру юлы белән дә хәбәр итү;

– һөнәри ориентация хезмәте күрсәтү системасын үстерү;

– эшсез яшьләрне эш белән вакытлыча тәэмин итүне оештыру;

– һөнәри белем бирү учреждениеләрендә яшьләргә һәнәр өйрәтү гамәлгә ашырыла торган һөнәрләр һәм белгечлекләр исемлекләрен, шулай ук хезмәт базарындагы ихтыяҗны исәпкә алып, яшь белгечләр саны турындагы исемлекләрне төгәлләштерү;

– эшкуарлык эшчәнлеген оештыруда яшьләргә актив ярдәм итү.

## Инвалидларны эш белән тәэмин итү

Хезмәткә сәләте чикле булган гражданнарга ярдәм итү өлкәсендә дәүләт сәясәте аларның потенциаль мөмкинлекләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле шартлар тудыруга юнәлдерелә.

Әлеге максатларга ирешү өчен өстәмә чаралар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

– инвалидларны эшкә урнаштыруга, аларга һөнәри ориентация, белем бирүгә, яңа һөнәргә өйрәтүгә, хезмәт эшчәнлегенә яраклаштыруга ярдәм итәрлек шартлар тудырудан;

– махсуслаштырылган предприятиеләр базасын ныгытудан;

– инвалидлар өчен яңа эш урыннары булдыручы һәм гамәлдәгеләрен саклаучы эш бирүчеләрне кызыксындырудан;

– эш бирүчеләрнең инвалидларның хезмәтенә түләү чыгымнарын өлешчә компенсацияләүдән;

– инвалидларны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт һәм җәмәгать берләшмәләре эшчәнлеген координацияләүдән;

– өйдә торып эшләү һәм үзмәшгульлекнең рәвешләрен кызыксындырудан һәм ярдәм итүдән;

– инвалидларны эшкә алу өчен квоталар булдырудан, бу чаралар 320 – 350 инвалидны эш белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

**Хатын-кызларны эш белән тәэмин итү**

Хатын-кызларны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп бурычлары:

– аларның хезмәт хокукларын гамәлгә ашыру өчен оештыру, икътисадый һәм хокукый гарантияләр булдыру;

– хатын-кызларның эшсезлеген кисәтүне тәэмин итү;

– эш урыннарын саклап калу һәм яңаларын булдыру;

–яңа һөнәргә өйрәтү, эшкуарлык эшчәнлеге нигезләренә төшендерү юлы белән хатын-кызларның хезмәт базарындагы конкурентлылыгын тәэмин итү;

– квалификация һәм хезмәт өчен түләү дәрәҗәсе буенча артта калуны бетерү;

– эшсез хатын-кызларга матди ярдәм күрсәтү һәм социаль гарантияләр тәэмин итү.

Хатын-кызларның эшсезлек проблемаларын хәл итү максатларында түбәндәге чаралар күздә тотыла:

– «Эш эзләүчеләр клубы» һәм «Яңа старт» программалары буенча эшсез хатын-кызларга хезмәт базарына ияләшүдә психологик ярдәм итү (ел саен кимендә 1,0 мең кеше);

– хезмәт базарындагы хәлләр, һөнәргә ихтыяҗлар, яңа һөнәргә өйрәтү мөмкинлеге мәсьәләләре буенча һөнәри ориентация хезмәте күрсәтү (ел саен кимендә 30,0 мең кеше);

– булган вакансияләргә һәм квоталанучы эш урыннарына эшкә урнаштыру;

– вакытлы һәм җәмәгать эшләрен оештыру (ел саен кимендә 8,0 мең хатын-кыз өчен);

– һөнәргә өйрәтүне, шул исәптән эшкуарлык эшчәнлеге нигезләренә, эшкуарлыкны һәм үз-үзеңне эш белән тәэмин итүне үстерүгә ярдәм итә торган һөнәрләргә һәм белгечлекләргә өйрәтүне оештыру (ел саен кимендә 4,5 мең кеше);

– эшкуарлык эшчәнлеген булдыруның башлангыч стадиясендә консультация, оештыру ягыннан ярдәм итү һәм булышу;

– эшкуарлыкны һәм үз-үзеңне эш белән тәэмин итүне үстерү буенча конференцияләр, семинарлар оештыру һәм уздыру, хатын-кыз иҗатын чагылдыручы һәм хатын-кызларның эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүенә ярдәм итә торган ярминкәләр уздыру;

– хатын-кызларның эшкуарлык инициативалары конкурсларын уздыру;

– социаль һәм хезмәт өлкәләрендә хокукый яклау мәсьәләләре буенча консультация бирү;

– хезмәт һәм эш белән тәэмин итү өлкәсендә гамәлдә булган законнарга һәм норматив хокукый актларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, аларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү өчен аларны хосусый секторда ялланып эшләүче хатын-кызларның яклanышы ягыннан анализлау.

## Җәза үтәүче учреждениеләрдән азат ителеп кайткан гражданнарны эш белән тәэмин итү

Эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү белән бергә гомуми нигезләрдә түбәндәге чараларны гамәлгә ашыру күздә тотыла:

– җәза үтәүче учреждениеләрдән азат ителеп кайткан затлар өчен эш урыннарын квоталау;

– җәза үтәүче учреждениеләрдән азат ителеп кайткан, шул исәптән амнистиягә бәйле азат ителгән затларга һөнәри ориентация хезмәте күрсәтү һәм психологик ярдәм итү, һөнәр белеме алырга җибәрү, шулай ук

вакытлыча эшкә урнаштыру буенча махсуслаштырылган программаларның аерым төрләре буенча аларны өстенлекле рәвештә эшкә урнаштыру;

– ирегеннән мәхрүм итү рәвешендәге җәзага хөкем ителүчеләрне эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтүнең максатчыл программаларын әзерләү һәм гамәлгә ашыру.

### 3.5 Запаска җибәрелергә тиешле хәрби хезмәткәрләргә, хәрби хезмәттән җибәрелгән гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итү

Запаска җибәрелергә тиешле хәрбиләргә, хәрби хезмәттән җибәрелгән гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итүнең төп нигезләре түбәндәгеләр булырга тиеш:

– хәрби хезмәттән җибәрелгән хәрби хезмәткәрләрне һәм аларның гаилә әгъзаларын эшкә урнаштыру һәм яңа һөнәргә өйрәтү ихтыяҗы буенча тикшеренүләр һәм анализ уздыру;

– хәрби хезмәттән җибәрелгән гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына аларны эшкә урнаштыру һәм яңа һөнәргә өйрәтү мәсьәләләрендәге ташламалар һәм хокуклар турында, шулай ук республиканың хезмәт базарындагы вәзгыять турында мәгълүмат бирүгә юнәлдерелгән гамәлләрне арттыру;

– хәрби хезмәттән җибәрелгән гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларын эшкә урнаштыру өчен өстәмә эш урыннары булдыруда эш бирүчеләргә ярдәм күрсәтү;

– хәрби хезмәттән җибәрелгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары өчен дәүләт оешмаларында һәм предприятиеләрендә эш урыннарын квоталау механизмын әзерләү;

– хәрби хезмәттән җибәрелгән гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларын һөнәргә өйрәтүгә өстенлекле юнәлеш бирү. Хәрби хезмәттән сәламәтлеге буенча яисә оештыру-штат гамәлләренә бәйле рәвештә пенсиягә чыгу хокукы белән киткән гражданнарга уку чорында, стипендия түләмичә генә, бушлай һөнәр белеме алуны тәэмин итү;

– хәрби хезмәттән җибәрелгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары өчен бизнес-планнар әзерләүдә консультацияләр бирү һәм ярдәм итү, аларның эшкуарлык эшчәнлегенә һәм үз-үзләрен эш белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән һөнәр белеме бирүне оештыру, шулай ук аларга укуларын тәмамлаганнан соң үз эшен ачуда тиешле финанс ярдәме күрсәтү;

– хәрби хезмәттән җибәрелгән гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларын һөнәргә өйрәтү һәм эшкә урнаштыру өлкәсендә эшләүче белгечләр әзерләүне камилләштерүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру;

– элеккеге хәрбиләр һәм аларның гаилә әгъзалары белән һөнәри ориентацияне, һөнәргә өйрәтүне һәм эшкә урнаштыруны яхшырту эшенең уртак процессын тәэмин итү максатларында хәрби комиссариатлар белән хезмәттәшлек итүне камилләштерү;

– хәрби хезмәттән җибәрелгән гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына бирелгән ташламаларның һәм гарантияләрнең халыкны эш белән тәэмин итүнең шәһәр һәм район үзәкләре тарафыннан үтәлешен даими рәвештә тикшереп тору;

– хәрби хезмәттән җибәрелгән хәрби хезмәткәрләрнең һәм гражданнарның иҗтимагый берләшмәләре белән бергә, әлеге категория гражданнарын эшкә урнаштыру һәм яңа һөнәргә өйрәтү буенча уртак эшләү нәтиҗәлелеген арттыру.

### 3.6 Монопрофильле шәһәрләрдә эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү

Җитештерүнең моноикътисадый структурасы өстенлек итә торган шәһәрләрдә эш белән тәэмин итү сәясәте иң элек эшсезлекне арттырмауга һәм эшсезләргә социаль ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелергә тиеш.

Эшсезлекне арттырмауга юнәлдерелгән гамәлләрнең берсе яңа эш урыннары булдырудан гыйбарәт. 2001 елда мондый шәһәрләрдә эш бирүчеләр акчалары исәбенә кимендә 8,1 мең эш урыны булдыру күздә тотыла.

89

Җирле хезмәт базарларында эш белән тәэмин итүнең дәүләт сәясәте башлыча халыкны эш белән тәэмин итүгә һәм аларны социаль яклауга ярдәм күрсәтүнең шәһәр һәм район программалары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Предприятиеләрдән хезмәткәрләрне күпләп җибәргән очракта түбәндәгеләрне гамәлгә ашыру күздә тотыла:

— әлеге предприятиедә, шулай ук аннан читтә дә, яңа эш урыннары булдырып, эштән җибәрелгән хезмәткәрләрне эшкә урнаштыру өчен, бу хезмәткәрләрне вакытлыча эш белән тәэмин итү өчен чаралар күреп, социаль планнар әзерләү;

— предприятиеләрдәге артык хезмәткәрләрне этаплап җибәрү программаларын әзерләү.

Республиканың хезмәт базарында кризис күренешләр барлыкка килгәндә, эшсезлек масштаблары киңәйгән очракта түбәндәге чаралар күреләчәк:

— эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү гамәлләрен тормышка ашыру өчен бүлеп бирелгән акчаларны бүлү, беренче чиратта, «Халыкны эш белән тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законында эшсезләргә социаль ярдәм күрсәтүнең гарантияләнгән нормаларын тәэмин итү өчен, хезмәт базарындагы аеруча киеренке вәзгыятьне бетерү өчен шәһәрләргә һәм районнарга бүлеп бирү;

— эшсез гражданнарга өстенлекле матди ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән чыгымнарның структурасын яңадан карап чыгу;

— халыкны эшсезлектән ирекле рәвештә иминләштерү системасын әзерләү һәм булдыру;

— күпләп эштән җибәрелү куркынычы булган хезмәткәрләрне яңа һөнәргә өйрәтү буенча эш белән тәэмин итү дәүләт хезмәтенең хезмәт күрсәтүләрен киңәйтү;

— эш бирүчеләрнең һәм җирле бюджетларның акчаларын җәлеп итеп, иҗтимагый эшләрне һәм вакытлыча эш белән тәэмин итүне оештыруның күләмнәрен киңәйтү;

— һөнәргә өйрәтүнең махсуслаштырылган программалары системасын гамәлгә ашыру;

— эшсез гражданнарның һәм эш белән тәэмин ителмәгән халыкның һөнәри ориентациясен һәм аларга психологик ярдәм күрсәтү системасын киңәйтү.

## 4. Хезмәт базары эшчәнлеген яхшырту

### 4.1. Хезмәт базарында социаль партнерлык

Хезмәткәрләрнең, эш бирүчеләрнең һәм дәүләтнең социаль ролен үзгәртү социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен, күмәк хезмәт бәхәсләрен (конфликтларын) хәл итүне шартнамәчел җайга салуның нәтиҗәле механизмы буларак, социаль партнерлык системасын булдыру һәм үстерү мәсьәләләрен ашыгыч рәвештә хәл итүне таләп итә.

Бүген предприятиеләрнең кадрлар буенча куәтен саклап калуда, эш урыннарын булдыруда һәм саклап калуда, хезмәткәрләрне җитештерүнең үзендә яңа һөнәргә өйрәтүдә, хезмәткәрләрне эшсезлектән яклауда, эштән җибәрелгән хезмәткәрләргә социаль гарантияләр бирүдә эш бирүчеләрнең җаваплылыгы арта бара.

Базар икътисадына күчү шулай ук хезмәт хакын эшче көчләрнен бәясенә карап түләүгә күчүне дә аңлата. Мондый очракта хезмәт хакын оештыру буенча базар моделенең үзәк звеносы булып хезмәт хакын күмәк шартнамәчел җайга салу системасы тора. Ул эш бирүчеләрнең һәм төрле дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең вәкилләре (һөнәр берлекләре) белән турыдан-туры сөйләшүләр алып бару нигезендә хәл ителә, мондый сөйләшүләрдә аерым предприятиенең шушы көндәге дәрәҗәсе, факторлар күплегенең хезмәт хакы күләменә йогынтысы, мәсәлән, җәмгыятькә кирәкле продуктның зурлыгы үзгәрү, эшче көчләргә ихтыяҗ үзгәрү һәм дәүләтнең хезмәт базарына йогынтысын җайга сала торган тәкъдимнәр истә тотылырга тиеш.

Мондый шартларда, халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте белән бергәләп, халыкның төрле төркемнәре (эш бирүчеләр, хатын-кызлар, яшьләр, инвалидлар һәм һ.б.) ихтыяҗларын яктыртучы иҗтимагый берләшмәләрнең эшсезлек артуны киметү һәм, аларны эшкә җәлеп итү юлы белән, хезмәт мохитен тотрыкландыру (шул исәптән шартнамәчел нигезләрдә дә), махсус проблемаларны хәл итү: халыкның аерым төркемнәрен эшкә урнаштырырга ярдәм итү, иҗтимагый эшләр уздыру, яшүсмерләр, яшьләр һәм башка шундыйлар белән эшләүгә ярдәм итү ролен арттырырга кирәк.

**4.2. Халыкны эш белән тәэмин итү сәясәтенә мәгълүмат ярдәме күрсәтү**

Хезмәт базарындагы вәзгыятьнең даими рәвештә үзгәреп торуы халыкка яңа мәгълүмат хезмәтләре күрсәтүне таләп итә. Мәсәлән, гражданнарга һәм эш бирүчеләргә хезмәт базарын үстерү турында, эшкә урнаштыру, һөнәргә өйрәтү һәм яңа һөнәргә өйрәтү перспективлары турында мәгълүмат бирү юлы белән хезмәт базарындагы вәзгыятьне яхшырту мөмкинлеге тудырыла. Нәтиҗәдә мөстәкыйль рәвештә эш эзләү шанслары арта, предприятиеләрнең кадрлар сәясәтендә әзерлеклерәк карарлар кабул ителә. Болар барысы да эшкә урнашу мөмкинлеге турында, шөгыльләр һәм карьера турында, эшче көчләргә ихтыяж тенденцияләре турында халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре тарафыннан таратылучы мәгълүматны киңәйтүне күздә тота.

Эш белән тәэмин итү өлкәсендә конъюнктураның үзгәрүенә оператив игътибар итү максатларында, халыкны эш белән тәэмин итүнең дәүләт сәясәтенә мәгълүмат ярдәме күрсәтү системасын формалаштыруны дәвам итәргә кирәк, ул түбәндәгеләрне күздә тотарга тиеш:

– социаль-хезмәт өлкәсендә мониторингны камилләштерүне;

– хезмәт һәм эш белән тәэмин итү мәсьәләләренә индикатив идарә итү системасын үстерүне;

– эш белән тәэмин итүнең иң актуаль проблемалары буенча фәнни тикшеренүләрне җайга салуны һәм уздыруны;

92

– хезмәт базарының торышы һәм эш белән тәэмин итү хезмәтенең эшчәнлеге турында мәгълүмат җыю һәм анализлау системасын модификацияләү һәм яхшырту гамәлләрен тормышка ашыруны;

– электрон мәгълүмат чаралары аша хезмәт базарының торышы турында халыкка һәм эш бирүчеләргә мәгълүмат бирүне;

– эш белән тәэмин итү хезмәтенә мөрәҗәгать итүче гражданнарга хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшырту, эшсезлек буенча пособиеләрне дөрес һәм вакытында исәпләүне тәэмин итү өчен эш белән тәэмин итү хезмәтен алга таба да мәгълүматлаштыруны.

Соңгы вакытта икътисад үсеше тенденциясе хезмәт базарына яңа эшче көчләр китерүне таләп итә, беренче чиратта, аларны җәлеп итәргә яисә әзерләргә кирәк. Шул ук вакытта гражданның эш эзләү вакытын һәм предприятиедә вакансияләрне рәсмиләштерү чорын кыскарту максатларында вакансиядәге эш урыннары потенциалыннан нәтиҗәле файдалануның зарурлыгы арта бара. Шушы юнәлештә түбәндәге эшләрне дәвам итү күздә тотыла:

– эшкә урнашу мөмкинлекләре турында халыкка мәгълүмат бирү өчен вакансияләр банкына ярдәм күрсәтү;

– югары квалификацияле белгечләрнең вакансияләр банкын булдыру һәм алып бару;

– халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренең һәм эш бирүчеләрнең үзара хезмәттәшлеген камилләштерү өчен өстәмә индикаторлар системасын кертү;

– эш бирүчеләр таләбе буенча уңайлы эш урыннарын һәм шул эш урыннарына туры килә торган хезмәткәрләрне сайлау;

– мәгълүматлар алмашуның Интернет, электрон почта (E-mail) кебек заманча яңа технологияләреннән файдалану;

– «Вакансияләр ярминкәләрен» һәм «Белгечләр ярминкәләрен» уздыру.

Эшкә урнаштыруга ярдәм итү буенча эшләрне оештыруның төп принциплары түбәндәгеләр: эш белән тәэмин итү хезмәтенә мөрәҗәгать итүче гражданнарга индивидуаль якын килү, аларга квалификацияле

ярдәм күрсәтергә тырышу, ягъни халыкны эш белән тәэмин итү турында гамәлдә булган законнарда каралган мәҗбүри функцияләрне тормышка ашыру.

2001 – 2003 елларда мәгълүмат-нәшрият эшчәнлеге түбәндәгеләргә юнәлдереләчәк:

– хезмәт базарының торышы турында, республика халкын эш белән тәэмин итү программасын гамәлгә ашыру турында халыкка һәм эш бирүчеләргә массакүләм мәгълүмат чаралары аша, шул исәптән эш белән тәэмин итү хезмәтенең махсуслаштырылган көндәлек басмалары аша мәгълүмат бирүне арттыру;

– халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренең клиентлары һәм эш бирүчеләр өчен буклетлар, брошюралар, мәгълүмат язмалары һәм башка көндәлек басмалар чыгару һәм тарату аша мөстәкыйль эш эзләүгә ярдәм итү;

– вакансияле эш урыннары турындагы белешмәләрне бастырып чыгару юлы белән гражданнарга эшкә урнашырга ярдәм итү.

## 5. Эшсез гражданнарга керем буенча ярдәм күрсәтү

Эшсез гражданнарга актив рәвештә эш эзләү чорында керемнәр буенча дәүләт ярдәмен күрсәтү түбәндәге юнәлешләрдә гамәлгә ашырыла:

– эшсезлек пособиесен түләү;

– бүтәннәр тәрбиясендә торучыларга өстәмә түләү;

– эшсез гражданнарның балалары өчен җәйге ялны оештыруны да кертеп, эшсезләргә матди һәм бүтән ярдәм күрсәтү;

– эшсез гражданнарга вакытыннан алда пенсия рәсмиләштерү.

Эшсезлек пособиесе ай саен 2001 елда– 18,4 мең, 2002 елда – 19,6 мең, 2003 елда 20,0 мең эшсез гражданга түләнәчәк.

Матди һәм бүтән ярдәм 2001 елда – 3,5 мең, 2002 елда – 3,3 мең, 2003 елда 3,0 мең эшсез гражданга күрсәтеләчәк.

Эшсез гражданнарга ял итү һәм сәламәтләнү өчен бүтәннәр белән бертигез хокуклар бирү максатларында, эшсез гражданнарга керем ярдәме

94

күрсәтү буенча халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре эшчәнлегенең төп юнәлешләреннән берсе итеп эшсез гражданнар балаларының ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру гамәлләрен уздыру күздә тотыла.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларын тәрбияләүче, инвалид балаларны караучы эшсез хатын-кызлар, ялгызак һәм күп балалы ата-аналар әлеге акчаларны алуда өстенлекле хокуктан файдаланачаклар.

Вакытыннан алда пенсиягә китү чыгымнары 2001 елда – 3,0 мең, 2002 елда – 2,5 мең, 2003 елда 2,0 мең гражданга тотылачак.

## 6. Программаны финанслау

Программаны финанслау чыгымнары Россия Федерациясенең Хезмәт һәм социаль үсеш министрлыгы методикасы нигезендә билгеләнә.

Салым турындагы законнарны үзгәртүгә бәйле рәвештә программаны гамәлгә ашыру федераль бюджет һәм Татарстан Республикасының республика бюджеты акчаларыннан финанслау шартларында башкарылачак. Программаны гамәлгә ашыру өчен 1404,1 млн. сум чыгым тоту карала,

шул исәптән:

| | |
|---|---|
| 2001 елда | 378,96 млн.сум |
| 2002 елда | 440,20 млн.сум |
| 2003 елда | 584,94 млн.сум |

Акчаның 49 процентка якыны – эшсезләр дип танылган затларга матди ярдәм күрсәтү программаларын, 34 проценты – эш белән тәэмин итүнең актив сәясәте программасын һәм 17 проценты бүтән программаларны гамәлгә ашыруга юнәлдереләчәк.

Программаны Федераль бюджет һәм Татарстан Республикасының республика бюджеты акчаларыннан финанслау күләмнәре тиешле елга бюджет проектлары әзерләгәндә ел саен билгеләнгән тәртиптә төгәлләштереләчәк.